# КАРАР

**2022 елның 22 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Важашур авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегенең Важашур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Важашур авылының Киров, Сахалин, Яшел урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Важашур авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Важашур авылы Киров урамындагы су челтәрләрен карап тоту, ремонтлау һәм урнаштыру; проект-смета документлары;
- Важашур авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу

?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 78 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 41.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 41 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Важашур авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегенең Важашур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия

Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Важашур авылының Киров, Сахалин, Яшел урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Важашур авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Важашур авылы Киров урамындагы су челтәрләрен карап тоту, ремонтлау һәм урнаштыру; проект-смета документлары;
- Важашур авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л.Иванов